| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛАБУГА<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

«28» май 2024 ел Алабуга шәһәре № 352

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының
«Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс уздыру
тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 20 апрелендәге
221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

**КАБУЛ ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 20 апрелендәге 221 номерлы карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе вазифасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 20 апрелендәге 221 номерлы карарының 2 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 3 бүлектә:

1) 3.2 пунктның 3.2.5. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.5. район Башлыгы белән килештереп билгели һәм Башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын вазифаларыннан азат итә, алар арасында вазифаларны бүлә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм район Башкарма комитетының башка хезмәткәрләре вазифасына билгеләп куя һәм ваззифаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана;».

2) 3.5 пунктын 3.5.10 пунктчасы белән түбәндәге редакциядә тулыландырырга:

«3.5.10. яллаучының (эш бирүченең) вәкиленә, яллаучының (эш бирүченең) вәкиле карары буенча үзгәртелгән мәгълүматлардан тыш, 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законның 15.2 маддәсендә каралган анкетадагы мәгълүматларның аңа билгеле булган үзгәрешләре турында язма рәвештә хәбәр итәргә (алга таба - анкетадагы мәгълүматлар).».

3) 3 бүлекнең 3.5.8 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2.2. 9 бүлектә:

1) 9.2 пунктның 2 пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

2) 9.3 пунктында Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов